РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

11.08.2026 **Чистай ш.** № 109

Чистай шәһәр Башкарма комитетының
«Стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру схемасын раслау турында»
2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан көйләү нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 нчы маддәсен, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларын үтәү йөзеннән, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Кушымта нигезендә 137 пункт өстәп, Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына өстәмәләр кертергә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтына (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитетының сәүдә, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече Ю. Ю. Әхмәтовага йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы С.А. Плотников

Чистай шәһәр
Башкарма комитеты
карарына кушымта
11.08.2026 ел № 109

Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объекты урнашкан урын | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 137. | Чистай шәһәре, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 44Б й. | Су | Вендинг аппараты | 1 | ел дәвамында |